Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

20.12.2024 Менделеевск ш. № 278

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы бюджеты турында

1 статья

1. 2025 елга Менделеевск муниципаль районы бюджетының төп характеристикалары расларга:

1) Менделеевск муниципаль районы бюджетыныж фаразлана торган күләме 1 341 543,59 мең сум;

2) Менделеевск муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 341 543,59 мең сум;

1) 3) Менделеевск муниципаль районы бюджеты кытлыгы 0 мең сум күләмендә.

1. Менделеевск муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын 2026 һәм 2027 елга расларга:

1) Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен:

- 2026 елга 1 427 455,32 мең сум;
- 2027 елга 1 524 825,56 мең сум

2) Менделеевск муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:

- 2026 елга 1 427 455,32 мең сум, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар 33 476,20 мең сум;
- 2027 елга 1 524 825,56 мең сум, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар 70 794,20 мең сум;

3) Менделеевск муниципаль районы бюджеты кытлыгы 2026 елга 0 мең сум күләмендә; Менделеевск муниципаль районы бюджеты кытлыгы 2027 елга 0 мең сум күләмендә;

3.Менделеевск муниципаль районы бюджеты кытлыгын 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. 2026 елның 1 гыйнварына Менделеевск муниципаль районыны бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген

0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә расларга

2. 2027 елның 1 гыйнварына Менделеевск муниципаль районыны бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә расларга

3. 2028 елның 1 гыйнварына Менделеевск муниципаль районыны бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә расларга

3 статья

Менделеевск муниципаль районы бюджетында әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

4 статья

2025 елда Менделеевск районы бюджетына 2024 ел йомгаклары буенча салымнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләгәннән соң калган Менделеевск муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре табышының бер өлешен кертү күрсәтелгән табышның 30% күләмендә 2025 елның 1 июленә кадәр башкарыла дип билгеләргә.

5 статья

1. Бюджет ассигнованиеләрен 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Менделеевск муниципаль районы чыгымнарының 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына ведомство структурасын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга:

- 2025 елга 29 300,9 мең сум;
- 2026 елга 30 046,5 мең сум;
- 2027 елга 30 934,2 мең сум;.

6 статья

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен әлеге карарга 5 кушымта нигезендә расларга:

- 2025 елга 26 253,06 мең сум;
- 2026 елга 20 310,85 мең сум;
- 2027 елга 20 703,15 мең сум;

7 статья

1. Менделеевск муниципаль районы бюджетында төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру

өчен җирлекләр бюджетларыннан алына торган бюджетара трансфертлар күләмен исәпкә алырга:

- автомобиль юлларын төзү, карап тоту һәм ремонтлау, төзекләндерү:
- 2025 елга 14 338,5 мең сум;
- 2026 елга 14 893,8 мең сум;
- 2027 елга 15 873,9 мең сум;
- Торак фондны капиталь ремонтлау
- 2025 елга 12 919,0 мең сум;
- 2026 елга 12 919,0 мең сум;
- 2027 елга 12 919,0 мең сум;
- тышкы муниципаль финанс контроле:
- 2025 елга 131,6 мең сум;
- 2026 елга 131,6 мең сум;
- 2027 елга 131,6 мең сум;

әлеге карарга 6 кушымта нигезендә бүленеп бирелә

8 статья

1. Менделеевск муниципаль районы бюджетында муниципаль учреждениеләрне тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен җирле бюджетлардан муниципаль районнар бюджетларына субсидияләр күләмен әлеге карарга 7 кушымта нигезендә исәпкә алырга:
- 2025 елга 87 179,76 мең сум;
- 2026 елга 86 055,55 мең сум;
- 2027 елга 90 736,55 мең сум;

9 статья

Җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының беренчел хәрби органнарын гамәлгә ашыруга авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр күләмен, әлеге карарга 8 кушымта нигезендә:
- 2025 елга 2 561,9 мең сум;
- 2026 елга 2 801,8 мең сум;
- 2027 елга 2 902,4 мең сум;

10 статья

Әлеге карарга 9 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар күләмен Менделеевск муниципаль районы бюджетында исәпкә алырга:
- 2025 елга 691 108,43 мең сум;
- 2026 елга 742 120,67 мең сум;
- 2027 елга 800 291,21 мең сум;

11 статья

Менделеевск муниципаль районы юл фонды бюджет ассигнованиеләрен расларга:
- 2025 елга 14 058,6 мең сум;

- 2026 елга 14 572,6 мең сум;
- 2027 елга 15 025,8 мең сум;

Һәм Менделеевск муниципаль районының гомуми кулланылыштагы муниципаль әһәмияттәге юлларында 2025, 2026 һәм 2027 елларга юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.

12 статья

"Менделеевск муниципаль районы бюджетына кертелгән салым булмаган керемнәр әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләүдән, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләрдән, шулай ук мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә түләүләрдән, Әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына мәҗбүри таләпләр бозылу нәтиҗәсендә китерелгән зыянны ирекле түләгәндә әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләүгә, әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү эшләрен оештыруга һәм бәяләүгә, әйләнә-тирә мохиткә хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яисә) киметү, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларын нәтиҗәле файдалану һәм торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасы табигатьне саклау чаралары планы нигезендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы белән килештереп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма хакимият органы белән килештереп, җибәрелә» дип билгеләргә.

13 статья

1. Менделеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнарына 2025 елда Менделеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.
2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2025 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

14 статья

Менделеевск муниципаль районы бюджетының 2025 елның 1 гыйнварына калган акчаларны, әлеге контрактларның шартлары нигезендә 2024 елда түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Менделеевск муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә 2025 елның 1 гыйнварына әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

15 статья

Менделеевск районы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты территориаль бүлекчәсе төзелгән килешүләр нигезендә

Менделеевск муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

16 статья

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: www.mendeleevsk.tatarstan.ru.

17 статья

Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Совет рәисе Р.И.Беляев